РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» июнь 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 164

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан муниципаль унитар предприятияләрдә булган күчемсез милекне сату һәм башкача читләштерү сделкаларын килештерү буенча карарлар кабул итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының антикоррупцион экспертизасы турында» Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2014 елның 29 июлендәге 233 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан муниципаль унитар предприятияләрдә булган күчемсез милекне сату һәм башкача читләштерү сделкаларын килештерү буенча карарлар кабул итү тәртибе турында» карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан муниципаль унитар предприятияләрдә булган күчемсез милекне сату һәм башкача читләштерү сделкаларын килештерү буенча карарлар кабул итү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

9 пунктында «һ.б.» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин